Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Майская Горка торак пункты территориясенең бер өлешендә

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 12 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлегенең Майская Горка торак пункты өлеше гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Майская Горка торак пункты өлеше территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 7100 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны
-Урман, Майская, Яшьләр урамнары буйлап юлларны кышкы чорда карап тотуга (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тыкырыктан алып Майская урамындагы 39 йортка кадәр сууткәргеч төзүгә (материал сатып алу һәм китерү, экскаватор эше, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Майская Горка торак пунктында чишмәләрне төзекләндерүгә (материал сатып алу һәм китерү, экскаватор эше, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Майская урамындагы 32 нче йорттан 34 нче йортка кадәр территорияне төзекләндерүгә (бетон сатып алу һәм китерү, сатып алу, китерү, декоратив агачлар һәм газон үләннәре утырту);

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлегенең Майская Горка авылы торак пунктында гражданнар җыенын 28.11.2020 елның 2 номерлы карары нигезендә гражданнарның җыелган үзара салымнарын буаны төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү); чишмәне төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү); балалар мәйданчыгын төзекләндерүгә (уен балалар җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру) - 33800 сум күләмендә, Майская Горка торак пунктында чишмәләрне төзеклә ндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү) юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы А.П. Морозов